СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2019 елның 15 ноябрендәге 88 номерлы**

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлеге җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында**

Муниципаль берәмлекләр территорияләрен тотрыклы үстерү, әйләнә-тирә мохитне һәм мәдәни мирас объектларын саклау өчен шартлар тудыру, муниципаль берәмлекләр территорияләрен планлаштыру өчен шартлар тудыру, физик һәм юридик затларның, шул исәптән җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү, инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру, шул исәптән җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның рөхсәт ителгән иң нәтиҗәле төрләрен сайлап алу мөмкинлеген бирү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 30, 33, 14, 15 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында»2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясы нигезендә Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ.:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 16 февралендәге 13-РС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә РФ икътисадый үсеше Министрлыгының 2014 елның 1 сентябрендәге 540 номерлы, 2019 елның 4 февралендә үзгәрешләре һәм өстәмәләре булган боерыгы белән расланган, куллануга рөхсәт ителгән төрләрен яраштыру өлешендә үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә керешергә;

2. Лаеш муниципаль районы башкарма комитетына проектны әзерләү һәм карап тоту тәртибе, сроклары турында физик һәм юридик затларның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны”Кама ягы” газетасына, http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында игълан итәргә: һәм http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирдән файдалану, төзелеш, төзекләндерү һәм экологик куркынычсызлык мәсьәләләре буенча Лаеш муниципаль районы Советының даими комиссиясенә йөкләргә .

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль район башлыгы-
Советы Рәисе урынбасары-- Т. П. Борһанова